| | | |
|---|---|---|
| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.12.2023 г. Казань № 774-170/кс-2023

Әлмәт муниципаль районы «Әлмәт җылылык челтәрләре» акционерлык җәмгыяте өчен кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасындагы кайнар суга 2024 елга тарифлар билгеләү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендәге тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 18.12.2023 №60-ПР утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Кайнар су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы Әлмәт муниципаль районы «Әлмәт җылылык челтәрләре» акционерлык җәмгыяте (алга таба – «Әлмәт җылылык челтәрләре» АҖ) тарафыннан җибәрелә торган кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасындагы кайнар суга әлеге карар кушымтасы нигезендә календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2024 елның 1 гыйнварыннан 2024 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Кайнар су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Әлмәт җылылык челтәрләре» АҖ ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 26 гыйнварындагы 108 номерлы карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу

стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 көннән соңга калмыйча ачарга.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
15.12.2023 № 774-170/кс-2023
карарына кушымта

«Әлмәт җылылык челтәрләре» АҖ тарафыннан кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасындагы кайнар суга 2024 елга календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Кайнар су белән тәэмин итүче оешма, муниципаль берәмлек исеме | Кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасындагы кайнар суга тариф (бер компонентлы), сум/куб.м | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | кайнар су белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системасы | | | | | | | |
| | | изоляцияләнгән терәкләр белән | | изоляцияләнмәгән терәкләр белән | | изоляцияләнгән терәкләр белән | | изоляцияләнмәгән терәкләр белән | |
| | | сөлге киптергечләр | | сөлге киптергечләр | | сөлге киптергечләр | | сөлге киптергечләр | |
| | | әйе | юк | әйе | юк | әйе | юк | әйе | юк |
| | | 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | | | | 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр | | | |
| | Әлмәт муниципаль районы | | | | | | | | |
| 1 | «Әлмәт җылылык челтәрләре» АҖ | | | | | | | | |
| 1.1 | Халык (тарифлар өстәмә хак салымын исәпкә алып күрсәтелгән)* | 184,58 | 173,66 | 195,72 | 184,58 | 213,83 | 201,82 | 228,24 | 215,75 |
| 1.2 | Башка кулланучылар (тарифлар өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелгән) | 153,82 | 144,72 | 163,10 | 153,82 | 178,19 | 168,18 | 190,20 | 179,79 |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясының 6 пунктын  үтәү максатларында аерып чыгарыла

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге